**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШӘРБӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

№ 4, 2021 нче елның 17 ноябре

**Шәрбән авыл җирлеге Башкарма комитетының «2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 2018 елның 27 февраленнән 1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, норматив-хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлеге Башкарма комитетының «2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасын раслау турында» 2018 елның 27 февраленнән 1 номерлы карары белән расланган 2017-2035 елларга Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Шәрбән авыл җирлегенең социаль инфраструктурасын комплекслы үстерү программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә::

1) «халыкны социаль инфраструктура объектлары белән тәэмин итүнең максатчан күрсәткечләре (Индикаторлары)» юлыннан соң түбәндәге эчтәлекле юл өстәргә:

| | |
|---|---|
| Социаль инфраструктура объектларын проектлау, төзү, реконструкцияләү буенча планлаштырылган чараларның (инвестицион проектларның) тасвирламасы | ҖҮИ бинасын төзү-2019 ел |

2) 1.4 пунктның 4 абзацында «муниципаль заказны формалаштыру» сүзләрен «муниципаль ихтыяжларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр сатып алуны гамәлгә ашыру» сүзләренә алмаштырырга, «максатчан» сүзен «Дәүләт, республика, муниципаль»сүзләренә алмаштырырга.;

2. Әлеге карарны Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга: http://aksubayevo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Аксубай муниципаль районы
Шәрбән авыл җирлеге башкарма
комитеты җитәкчесе Д.Ә.Шәрифуллин